**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«22» 05 2024 ел Яр Чаллы №2280

«2022-2024 елларга Тукай муниципаль районы авыл яшьләре» район комплексы программасын раслау хакында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 4 мартындагы 587 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Тукай муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисади активлыгын арттыру максатында, «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 4 мартындагы 587 номерлы карары белән расланган «2022-2024 елларга Тукай муниципаль районы авыл яшьләре» программасына 2024 елга «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесендә финанслау күләмен 200000,00 сум күләмендә арттырып үзгәрешләр кертергә.
2. «2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү» программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганагы» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганагы | Программаны финанслауның гомуми күләме район җирле бюджеты хисабына 21189849,43 сум тәшкил итә.<br>Шул исәптән гамәлгә ашыру еллары буенча:<br>2022 ел – 7465509,31 сум, шул исәптән «Тукай муниципаль районының яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесен агымдагы карап тотуга 6429773,51 сум;<br>2023 ел – 7932345,43 сум, шул исәптән «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесен агымдагы карап тотуга 7024783,10 сум; |

| | |
|---|---|
| | 2024 ел – 5791994,69 сум, шул исәптән «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесен агымдагы карап тотуга 4759994,69 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2022-2024 елларга Тукай муниципаль районы авыл яшьләре» район программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар «Тукай муниципаль районы яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесен карап тоту һәм яшьләр чараларын үткәрү» 19 пунктына 200000,00 сум финанс средстволарын өстәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә 3 эш көне эчендә әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1639031830